КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче
Кече Кибәче торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

12.11.2025 №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олы Кибәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 34 номерлы карары нигезендә, 2026 нчы елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Кече Кибәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау (Кече Кибәче торак пунктындагы зират коймасын кору) дигән сорау буенча 2026 нчы елның 12 нче ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 110 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 60 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _60_ы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Кибәче авыл җирлегенең Кече Кибәче торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2026 нчы елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Кече Кибәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау (Кече Кибәче торак пунктындагы зират коймасын кору) дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/kibiachi адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче: Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин